34

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР** № I-5

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 23 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисен билгеләп кую турында

«Россия Федерациясе субъектларының, федераль территорияләрнең һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 07.02.2011 ел, №6-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 28.03.2014 ел, №XXXVI-2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы регламенты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 13.12.2014 №XLII-3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмә нигезендә, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына Бәдретдинов Азат Ильдус улын билгеләргә.

2 . Әлеге карар кабул ителгән мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы / Совет Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан. Р.07-3577/02. ИНН 1634003087